Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының
Олыяз авыл җирлеге Советы

КАРАР

«22» февраль, 2024 ел № 6

Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Олыяз авыл җирлеге җирле үзидарәсенең үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы сайлап куелган вазыйфаи затларына, муниципаль хезмәткәрләренә хезмәт хакы түләү шартлары турында нигезләмәне раслау хакында

«Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007елның 02 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль законның 22 статьясы, Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексы, «Үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы депутатларга, җирле үзидарәнең сайлап куелган вазыйфаи затларына, Татарстан Республикасы муниципаль хезмәткәрләренә хезмәт хакы түләүгә чыгымнарны формалаштыру нормативлары турында» 2018 елның 28 мартындагы 182 номерлы Министрлар Кабинеты карары, Олыяз авыл җирлеге Уставы нигезендә Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Олыяз авыл җирлеге Советы **карар бирде:**

1. Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Олыяз авыл җирлеге муниципаль хезмәткәрләренә, җирле үзидарәнең үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы сайлап куелган вазыйфаи затларына хезмәт хакы түләү шартлары турында нигезләмәне расларга (кушымта итеп бирелә).

2. Кукмара муниципаль районы Олыяз авыл җирлеге Советының түбәндәге карарларын үз көчен югалткан дип танырга:

- «Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Олыяз авыл җирлеге муниципаль хезмәткәрләренә, җирле үзидарәнең үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы сайлап куелган вазыйфаи затларына хезмәт хакы түләү шартлары турында нигезләмәне раслау хакында» 2018 елның 05 июнендәге 12 номерлы,

- «Олыяз авыл җирлеге Советының 2018 елның 05 июнендәге 12 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Олыяз авыл җирлегенең үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларының, муниципаль хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында» 2018 елның 07 ноябрендәге 31 номерлы

- «Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Олыяз авыл җирлеге муниципаль хезмәткәрләренә, җирле үзидарәнең вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы сайлап куелган вазыйфаи затларына хезмәт хакы түләү шартлары турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында» 2020 елның 21 декабрендәге 14 номерлы

- «Олыяз авыл җирлеге Советының 2018 елның 05 июнендәге 12 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Олыяз авыл җирлегенең вәкаләтләрне даими нигездә гамәлгә ашыручы җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларының, муниципаль хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында» 2022 елның 30 декабрендәге 40 номерлы

3. Әлеге карарның гамәлдә булуы 2024 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Олыяз авыл җирлеге башлыгы: Р.Ф.Маликов

Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Олыяз авыл җирлеге Советының 2024 елның «22.» февралендэге 6 номерлы Карары белән расланган

# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КУКМАРА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ОЛЫЯЗ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ МУНИЦИПАЛЬ ХЕЗМӘТКӘРЛӘРЕНӘ, ҖИРЛЕ ҮЗИДАРӘНЕҢ ҮЗ ВӘКАЛӘТЛӘРЕН ДАИМИ НИГЕЗДӘ ГАМӘЛГӘ АШЫРУЧЫ САЙЛАП КУЕЛГАН ВАЗЫЙФАИ ЗАТЛАРЫНА ХЕЗМӘТ ХАКЫ ТҮЛӘҮ ШАРТЛАРЫ ТУРЫНДА НИГЕЗЛӘМӘ

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Олыяз авыл җирлеге муниципаль хезмәткәрләренә, җирле үзидарәнең үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы сайлап куелган вазыйфаи затларына хезмәт хакы түләү шартлары турында нигезләмә хезмәткә түләү хакы күләмен һәм шартларын билгели.

## 2. Муниципаль берәмлек башлыгының хезмәт хакы

2.1. Муниципаль берәмлек башлыгына айлык акчалата түләү түбәндәгедән артмаган күләмнәрдә билгеләнә:

| Вазыйфаның исеме | Акчалата түләүнең күләме (сумнарда) |
|---|---|
| | Унберенче төркем (халык саны 1,5 тән 5 мең кешегә кадәр) |
| Муниципаль берәмлек башлыгы | 19039 |

2.2. Тиешле елларны хезмәт иткән өчен айлык өстәп түләү айлык акчалата түләүгә карата процентлар белән түбәндәгедән артмаган күләмнәрдә билгеләнә:

| Муниципаль хезмәт стажы булганда | Өстәп түләүнең чик күләме (процент) |
|---|---|
| 1 елдан 5 елга кадәр | 5 |
| 5 елдан 10 елга кадәр | 10 |
| 10 елдан 15 елга кадәр | 15 |
| 15 елдан артык | 20 |

Тиешле елларны хезмәт иткән өчен айлык өстәп түләүгә чыгымнар күләме елына өч айлык акчалата түләү нормативыннан арта алмый.

2.3. Муниципаль берәмлек башлыгына еллык түләүле отпуск биргәндә бер тапкыр бирелә торган түләү айлык бер акчалата түләүдән артмаган күләмдә түләнә.

2.4. Айлык акчалата түләү нормативтан артмаган күләмдә түләнә: 11 нче төркемгә кертелгән муниципаль берәмлек башлыгы өчен – елга 10,36 айлык акчалата түләү 12 нче төркемгә кертелгән муниципаль берәмлек башлыгы өчен – елга 9,26 айлык акчалата бүләкләү.

## 3. Муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт хакы

3.1. Муниципаль хезмәткәрләргә муниципаль хезмәтнең билгән муниципаль вазыйфасына карап, авыл җирлегендә муниципаль хезмәт вазыйфаларының кече төркеме белгече вазыйфаи хезмәт хакына калдыксыз бүленә торган күләмдә 12688,0 сум

күләмендә вазыйфаи хезмәт хаклары билгеләнә.»;

Муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт хакын исәпләгәндә кулланыла торган коэффициентлар <u>1 нче кушымтада</u> билгеләнгән.

3.2. Тиешле елларны хезмәт иткән өчен айлык өстәп түләү муниципаль хезмәткәрнең хезмәт хакына карата процентлар белән түбәндәгедән артмаган күләмнәрдә билгеләнә:

| Муниципаль хезмәт стажы булганда | Өстәп түләүнең чик күләме (процент) |
|---|---|
| 1 елдан 5 елга кадәр | 5 |
| 5 елдан 10 елга кадәр | 10 |
| 10 елдан 15 елга кадәр | 15 |
| 15 елдан артык | 20 |

3.3. Муниципаль хезмәткәргә классլы чины өчен айлык өстәп түләү түбәндәгедән артмаган күләмнәрдә билгеләнә:

| Классլы чин | Классլы чин өчен өстәмә түләү күләме (вазыйфаи хезмәт хакына процентлар белән) |
|---|---|
| I классլы хакыйкый муниципаль киңәшче | 7 |
| II классլы хакыйкый муниципаль киңәшче | 5 |
| III классլы хакыйкый муниципаль киңәшче | 3 |
| I классլы муниципаль киңәшче | 7 |
| II классլы муниципаль киңәшче | 5 |
| III классլы муниципаль киңәшче | 3 |
| I классլы муниципаль хезмәт киңәшчесе | 7 |
| II классլы муниципаль хезмәт киңәшчесе | 5 |
| III классլы муниципаль хезмәт киңәшчесе | 3 |
| I классլы муниципаль хезмәт референты | 7 |
| II классլы муниципаль хезмәт референты | 5 |
| III классլы муниципаль хезмәт референты | 3 |
| I классլы муниципаль хезмәт секретаре | 7 |
| II классլы муниципаль хезмәт секретаре | 5 |
| III классլы муниципаль хезмәт секретаре | 3 |

3.4. Муниципаль хезмәтнең аерым шартлары (катлаулылык, киеренкелек, хезмәттә югары казанышлар, махсус эш режимы) өчен муниципаль хезмәткәрнең вазыйфаи хезмәт хакына ай саен өстәп түләү җирле үзидарә органы җитәкчесе тарафыннан түбәндәгедән артмаган күләмнәрдә билгеләнә:

| Муниципаль вазыйфасы | Муниципаль хезмәтнең махсус шартлары өчен өстәп түләү күләме (вазыйфаи хезмәт хакына карата процентлар белән) |
|---|---|
| югары муниципаль вазыйфалар өчен | 9 |
| төп муниципаль вазыйфалар өчен | 7 |

| | |
|---|---|
| әйдәп баручы муниципаль вазыйфалар өчен | 5 |
| югары муниципаль вазыйфалар өчен | 3 |
| кече муниципаль вазыйфалар өчен | 1 |

3.5. Муниципаль хезмәткәргә вазыйфаи хезмәт хакының 18 процентыннан артмаган күләмдә айлык акчалата түләү түләнә.

3.6. Муниципаль хезмәткәрләргә аеруча мөһим һәм катлаулы биремнәрне үтәгән өчен премияләр түләнә, аларны түләү тәртибен муниципаль органның бурычларын һәм функцияләрен үтәүне, вазыйфа инструкциясен үтәүне тәэмин итүне исәпкә алып, яллаучы вәкиле (эш бирүче) билгели.

3.7. Муниципаль хезмәткәрләргә билгеләнгән хезмәт хакы фонды чикләрендә матди ярдәм түләнә.

3.8. Еллык түләүле отпуск биргәндә бер тапкыр бирелә торган түләү муниципаль хезмәткәргә 1,2 вазыйфаи хезмәт хакыннан артмаган күләмдә башкарыла.

## 4. Муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәтенә түләү фондын формалаштыру

1. Вазыйфаи хезмәт хакын түләү өчен бүленә торган акча суммаларыннан тыш муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт хакын түләү фондын формалаштырганда, түләү өчен акча карала (елга исәпләгәндә 12 вазыйфаи хезмәт хакыннан чыгып):

1) классны чин өчен айлык өстәп түләү –вазыйфаи хезмәт хакының дүрт процентыннан артмаган күләмдә;

2) муниципаль хезмәттә тиешле елларны хезмәт иткән өчен айлык өстәп түләү – вазыйфаи хезмәт хакының унөч процентыннан артмаган күләмдә;

3) муниципаль хезмәтнең аерым шартлары (катлаулылык, киеренкелек, хезмәттә югары казанышлар, махсус эш режимы) өчен ай саен өстәп түләү – вазыйфаи хезмәт хакының биш процентыннан артмаган күләмдә;

4) аеруча мөһим һәм катлаулы биремнәрне үтәгән өчен премияләр – вазыйфаи хезмәт хакының бер процентыннан артмаган күләмдә;

5) еллык түләүле отпуск биргәндә бер тапкыр бирелә торган түләү – вазыйфаи хезмәт хакының ун процентыннан артмаган күләмдә;

6) айлык акчалата бүләкләү – вазыйфаи хезмәт хакларының 18 процентыннан артмаган күләмдә.

Олыяз авыл җирлеге башлыгы: Р.Ф.Маликов

Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Олыяз авыл җирлеге муниципаль хезмәткәрләренә, җирле үзидарәнең үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы сайлап куелган вазыйфаи затларына хезмәт хакы түләү шартлары турында нигезләмәгә 1 нче кушымта

Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Олыяз авыл җирлеге муниципаль хезмәткәрләренең вазыйфаи хезмәт хакларын исәпләгәндә кулланыла торган коэффициентлар таблицасы

| Вазыйфаларның исеме | Коэффициентлар |
|---|---|
| | Унберенче төркем (халык саны 1,5 тән 5 мең кешегә кадәр) |
| Башкарма комитет җитәкчесе | 1,50 |
| Башкарма комитет җитәкчесе урынбасары (секретаре) | 1,47 |

Олыяз авыл җирлеге башлыгы: Р.Ф.Маликов